| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 13.10.2023 | г. Казань | № 321-11/кс-2023 |

«ТеплоГрупп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.10.2023 № 43-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ТеплоГрупп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ТеплоГрупп» ҖЧҖ) өчен салкын суны транспортлаганга һәм агынты суларны транспортлаганга әлеге карар кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ТеплоГрупп» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.10.2023 № 321-11/кс-2023
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ТеплоГрупп» ҖЧҖ өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «ТеплоГрупп» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән)<br><br>су үткәрү челтәрләре:<br>Короленко урамы, 28Б;<br>Идел буе урамы, 210 (А, Б, В, Г, Д, Е, Ж);<br>Р.Нәҗметдинов урамы, 11, 11 к.2, 11 к.3, 11 к.4, 11 к.5, 2А;<br>Четаев урамы, 8;<br>Комсомол урамы, 2<br>Новаторлар урамы, 8Б<br><br>канализация челтәрләре:<br>Короленко урамы, 28Б;<br>Идел буе урамы, 210 (А, Б, В, Г, Д, Е, Ж); 214<br>Р.Нәҗметдинов урамы, 11, 11 к.2, 11 к.3, 11 к.4, 11 к.5, 2А;<br>Четаев урамы, 8;<br>Шоссейная урамы, 57. | 1,62 | 13,16 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге